ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 463-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.И. Галиев тарафыннан кертелгән «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 463-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2576-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
М.И. Галиев тарафыннан
кертелә

**«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 1 – 2; 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:
а) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;
б) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«агрохимикатлар – үсемлекләрне тукландыру һәм җирнең (туфракның) уңдырышлылыгын җайга салу өчен каралган ашламалар (минераль, органик, органик-минераль, микробиологик), химик мелиорантлар. Торф, терлекчелек һәм үсемлекчелек калдыклары, терлекчелекнең эшкәртелмәгән һәм яңадан эшләп чыгарылмаган өстәмә продуктлары, органик һәм органик-минераль ашламалар житештерү өчен кулланыла торган ләм, агым сулар утырмасы, катнаш минераль ашламалар агрохимикатлар булып саналмый;»;
в) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«пестицидлар – үсемлекләрнең үсешен җайга салу, феромоннар, дефолиантлар, десикантлар һәм фумигантлар итеп тә кулланыла торган матдәләр яисә матдәләр катнашмасы һәм корткыч организмнарга каршы көрәшү өчен каралган химик һәм биологик препаратлар;»;
г) унберенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

2) 4 статьяның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«үз милкендә яисә файдалануында булган хуҗалыгы җирләренең деградацияләнү, җир кишәрлекләрендә туфрак пычрану фактлары турында башкарма хакимиятнең тиешле органнарына хәбәр итәргә;»;

3) 7 статьяның бишенче абзацында «эрозиягә каршы чаралар комплексын керткән,» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

**«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты** (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү һәм «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 595 номерлы Закон) аерым нигезләмәләрен «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итүне дәүләт җайга салуы турында» 1998 елның 16 июлендәге 101-ФЗ номерлы (алга таба – 101-ФЗ номерлы Федераль закон), «Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән имин һәм зарарсыз эш итү турында» 1997 елның 19 июлендәге 109-ФЗ номерлы (алга таба – 109-ФЗ номерлы Федераль закон) Россия Федерациясе законнары нормаларына туры китерү максатында эшләнде.

101-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын дәүләт тарафыннан нормалаштыру;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең деградациясе;

агрохимик хезмәт күрсәтү.

101-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясында элек булган «туфракны пычрату», «эрозиягә каршы чаралар» төшенчәләре, «Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән хәвефсез эш итү турында» Федераль законның 22 статьясына һәм «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итүне дәүләт җайга салуы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 31 июлендәге 308-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылды.

Шуңа бәйле рәвештә республика законын 101-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы нормаларына туры китерү максатларында 595 номерлы Законның 1 статьясына тиешле үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә, анда «авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне пычрату» һәм «эрозиягә каршы чаралар» дигән төшенчәләрне аңлаткан алтынчы һәм унөченче абзацларны үз көчләрен югалткан дип тану тәкъдим ителә.

109-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясында аерым алганда «пестицидлар» һәм «агрохимикатлар» кебек төшенчәләр кулланыла.

109-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясында китерелгән «пестицидлар» һәм «агрохимикатлар» төшенчәләренә билгеләмә элегрәк «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 28 июнендәге 221-ФЗ номерлы, «Терлекчелекнең өстәмә продуктлары турында һәм Россия

Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законны кабул итүгә бәйле рәвештә төгәлләштерелде һәм яңа редакциядә бәян ителде.

Шулай итеп, закон проектында 109-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы таләпләре нигезендә 595 номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертергә: сигезенче һәм тугызынчы абзацларда «пестицидлар» һәм «агрохимикатлар» төшенчәсенең эчтәлеген төгәлләштереп, яңа редакциядә бәян итү тәкъдим ителә.

Шулай ук хәзерге вакытта595 номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы җиденче абзацының гамәлдәге редакциясе нигезләмәләре 101-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы җиденче абзацына тулысынча туры килми. Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән 4 статьяның җиденче абзацын яңа редакциядә бәян итү тәкъдим ителә.

Моннан тыш, закон проектында 595 номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы бишенче абзацына «эрозиягә каршы чаралар комплексы» сүзләрен төшереп калдырып, төзәтмәләр кертү карала.

Закон проектын кабул итү «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен федераль закон нормалары нигезендә бердәйләштерүгә, камилләштерүгә һәм актуальләштерүгә ярдәм итәчәк.

**«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми